РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**СОВЕТ ЧИСТОПОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**

***Решение*** ***Карар***

**2019 елның 26 сентябре** **Чистай шәһәре** **№ 47/6**

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Советының 2018 елның 18 июлендәге кабул ителгән “Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының “Чистай муниципаль районы” муниципаль берәмлеге милкенә караган, канәгатьләнмәслек хәлдә булган, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларының(тарихи һәм мәдәни һәйкәлләр) бердәм дәүләт реестрына кертелгән кулланылмый торган мәдәни мирас объектлары өчен ташламалы аренда түләве билгеләү тәртибен һәм “Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының “Чистай муниципаль районы” муниципаль берәмлеге милкенә караган, канәгатьләнмәслек хәлдә булган Россия Федерациясе халыкларының файдаланылмый торган мәдәни мирас объектларын (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләр) физик һәм юридик затларга арендага бирү тәртибен раслау турында”гы 35/4 нче номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында”гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга таянып, Татарстан Республикасы “Чистай муниципаль районы” муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Чистай муниципаль районы Советы

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Советының 2018 елның 18 июлендә кабул ителгән «Татарстан Республикасы “Чистай муниципаль районы” муниципаль берәмлеге милкенә караган, канәгатьләнмәслек хәлдә булган, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларының(тарихи һәм мәдәни һәйкәлләр) бердәм дәүләт реестрына кертелгән кулланылмый торган мәдәни мирас объектлары өчен ташламалы аренда түләве билгеләү тәртибен һәм “Татарстан Республикасы “Чистай муниципаль районы” муниципаль берәмлеге милкенә караган, канәгатьләнмәслек хәлдә булган Россия Федерациясе халыкларының файдаланылмый торган мәдәни мирас объектларын (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләр) физик һәм юридик затларга арендага бирү тәртибен раслау турында”гы 35/4 нче номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

17 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«17. Гамәлдәге законнар нигезендә, мәдәни мирас объектын арендалау килешмәсе төзү белән бер үк вакытта арендатор белән мәдәни мирас объекты урнашкан җир кишәрлеген арендалау килешмәсе төзелә.

Җир кишәрлеген арендалау килешмәсе мәдәни мирас объектын арендалау килешмәсе төзелгән көннән соң 60 көннән дә соңга калмыйча төзелә.

Әгәр җир кишәрлеге мәдәни мирас объектының фундаменты обрезы буенча формалашса, җир кишәрлеген арендалау килешүе төзелми. Бу очракта мәдәни мирас объектын арендалау шартнамәсенә мәдәни мирас объектының фундаменты обрезы буенча төзелгән җир участогының бер өлеше өчен аренда түләве кертелә. Җир кишәрлеге өчен аренда түләве күләме җир кишәрлекләре өчен аренда түләвен билгеләү тәртибен җайга салучы норматив хокукый актлар нигезендә билгеләнә.

Әгәр җир участогы формалашмаган һәм кадастр исәбенә куелмаган булса, шул ук вакытта арендатор тарафыннан мәдәни мирас объекты янындагы территория файдаланылмый икән, аренда килешүе төзү таләп ителми. Бу очракта мәдәни мирас объектын арендалау шартнамәсенә мәдәни мирас объектының фундаменты обрезы буенча исәпләнгән, җир участогының бер өлеше өчен түбәндәге формула буенча исәпләнгән аренда түләве кертелә:

$$ПР = \frac{Pan \times Пзу}{12} \times N$$

Пр- Объект астындагы җир кишәрлеге өчен түләү күләме;

Pan- Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Җир өчен аренда түләве турында” 1995 ел, 9 февраль, 74 нче карары нигезендә исәпләнгән еллык аренда түләве күләме, кв. м өчен сум.

Пзу- объект урнашкан мәйдан, кв. м.

N- объектлар урнашкан вакыт аралыгына айлар саны».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Чистай муниципаль районының рәсми сайтында (www.chistopol.tatarstan.ru.) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Чистай муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе һәм депутат эшчәнлеге мәсьәләләре буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Чистай муниципаль
районы башлыгы Д.А. Иванов